| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «СУГУШЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «СУГЫШЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕБАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 20 августы № 13

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларның туплану урынын билгеләү, аның урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 9 мартындагы 4 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында (2025 елның 21 июлендәге 12 номерлы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җитештерү һәм куллану калдыклары белән тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы, «Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында нигезләмәне раслау хакында», 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карарларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларның туплану урынын билгеләү, аның урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 9 мартындагы 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне (2025 елның 21 июлендәге 12 номерлы үзгәрешләр белән) кертергә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Үзәк урамы, 27 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы авылы, Узәк урамы, 27 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru/) «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сугышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П. Зыятдинова